**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июнь № 381

г. Казань

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2016 елда тормышка ашыру барышы һәм 2017 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2016 елда тормышка ашыру барышы һәм 2017 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе белән берлектә, 2017 елның 1 августына кадәр «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын тормышка ашыру нәтиҗәләрен карап тикшерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте хисабы структурасын Россия Федерациясендә энергия саклау торышы һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү турындагы дәүләт доклады белән бердәй итеп корректировкалау хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, тиешле энергетика ресурслары өчен түләүгә чыгымнар составында энергия сервисы контрактлары өчен чыгымнарны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе буенча методик тәкъдимнәрне эшләргә һәм бюджет чараларын алучы бюджет оешмаларын алга таба үстерү өчен энергия сервисы контрактлары кысаларында экономияләнгән бюджет акчасыннан файдалану хакында тәкъдимнәр әзерләргә.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына төзелгән ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасында җил энергетикасын үстерү буенча чаралар планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә:

2017 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен җылылык белән тәэмин итүнең энергия нәтиҗәлелеге рейтингларын формалаштыруны тәэмин итәргә, алга таба рейтинг нәтиҗәләрен төбәк мәгълүмат ресурсларында урнаштырырга;

2017 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына күпфатирлы йортларның һәм бюджет өлкәсе оешмалары биналары, корылмалары, төзелмәләренең энергия нәтиҗәлелеге буенча таләпләрне раслау турында тәкъдимнәр кертергә, шул исәптән ут-диодлы яктырткычлар һәм һава торышына бәйле автомат рәвештә көйләнә торган индивидуаль җылылык пунктлары урнаштыру шартларын үз эченә алган.

6. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына 2017 елның 1 сентябренә кадәр җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге программаларына таләпләрне билгеләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 27 сентябрь, 971 нче карары таләпләре нигезендә ут-диодлы яктылык чыганакларын гамәлгә кертү буенча күрсәткечләрне энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программаларына кертү мониторингын үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

Татарстан Республикасы ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрендә энергия сервисы шартнамәләре (контрактлары) механизмы аша энергия саклау чараларын гамәлгә ашырырга (булганда);

Татарстан Республикасы ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең мөлкәт комплексы белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру өчен «Энергия нәтиҗәлелеге» энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының аналитик механизмнарыннан файдаланырга.

8. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә энергия саклау чараларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда энергия сервисы шартнамәләрен (контрактларын) төзү юлы белән методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрдә энергия сервисы шартнамәләре (контрактлары) механизмы аша энергия саклау чараларын гамәлгә ашырырга;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә законнар таләпләрен искә алып, энергия саклауга һәм энергетика ресурсларын куллануның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән хезмәтләр күрсәтүгә энергия сервисы шартнамәсе (контракты) төзү хокукына конкурс документларының бертип формаларын кулланырга, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2016 елның 14 декабрендәге 328-ОД номерлы приказы белән расланган энергия сервисы шартнамәсе (контракты) һәм техник йөкләмә проектын кертеп; конкурс документларын Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килештерүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең мөлкәт комплексы белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру өчен «Энергия нәтиҗәлелеге» энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының аналитик механизмнарыннан файдаланырга;

бюджет оешмаларында һәм күпфатирлы йортларда энергетика ресурсларын куллануны исәпләү җайланмаларының төзеклеген һәм аларның күрсәткечләрен үз вакытында алуны тикшерүдә тоту өчен җаваплы затларны билгеләүне тәэмин итәргә;

2017 елның 1 июленә кадәр энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендәге муниципаль программаларны гамәлдәге норматив хокукый һәм методологик документларга туры китерергә, программаларның гамәлдә булу вакытларын 2020 елга кадәр озайтырга, аларның экспертизасын, раслануын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бердәм рәсми порталында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Каримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин